РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«8» декабрь 2019 ел г. Альметьевск №2096

Тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 28 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган турында» 2008 елның 4 апрелендәге 232 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карарын үтәү йөзеннән

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга (1 нче кушымта).
2. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2015 елның 23 гыйнварындагы 94 номерлы «Тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка. йөкләргә.

Район башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.Н. Подовалов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Зак. № 305-2000

Әлмәт муниципаль районы
башкарма комитетының
«8» декабрь 2019 ел №2096
крары белән расланган
1 нче кушымта

Тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы
торакны наемга тапшыру өчен опекунга
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТы

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан («Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган дәүләт вәкаләтләре кысаларында) тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны Татарстан республикасы Әлмәт муниципаль районы тарафыннан наемга тапшыру өчен опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба-хезмәт күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Хезмәт алучылар: Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар (алга таба-мөрәҗәгать итүчеләр).

1.3. Хезмәт Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә. Хезмәтне башкаручы: Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының «Опека» идарәсе (алга таба – «Опека»идарәсе).

1.3.1. «Опека» идарәсе урыны: Татарстан Республикасы, Әлмәт ш., Шоссейная ур., 1 Б.

«Опека» идарәсенең кабул итү графигы: сишәмбе 13:00-17:00, пәнҗешәмбе 8:00-12: 00.

1.3.2. Белешмә телефоннары: 8(8553) 32-89-72, 32-89-26, 32-90-74, 32-89-70.

1.3.3. Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә (алга таба – Интернет челтәре) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтының адресы: http://www.almetyevsk .tatar.ru.

1.3.4. Хезмәт турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1.3.4.1. Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен бинада урнашкан хезмәт турында визуаль һәм текст мәгълүматын үз эченә алган хезмәт турында мәгълүмат стендлары аша;

1.3.4.2. Интернет челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында (http://www.almetyevsk.ru);
- Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (http://uslugi.tatar.ru)

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

1.3.4.3. «Опека» идарәсенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән);

1.3.4.4. «Опека» идарәсенә язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә;

1.3.4.5. КФҮтә (КФҮ аша хезмәт күрсәтү шартларында).

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү сораулары буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында «Опека» идарәсе белгече тарафыннан урнаштырыла http://www. almetyevsk.tatar.ru мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен бинада мәгълүмати стендларда да бар.

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив актлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (1993 елның 12 декабрендә кабул ителде) (алга таба-РФ Конституциясе);

- 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Гражданнар кодексы (алга таба - РФ ГК);

- 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Россия Федерациясе торак кодексы (алга таба - РФ ТК);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнарның хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 02 июлендәге 3185-I номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба - 1992 елның 02 июлендәге 3185-I номерлы Россия Федерациясе Законы);

- «Күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-1997 елның 21 июлендәге Дәүләт теркәве турында ФЗ);

- «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба-152-ФЗ номерлы Федераль закон);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

- «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба - ТР МК ның 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары);

- Әлмәт муниципаль районы Советының 2011 елның 22 сентябрендәге 116 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы уставы (үзгәрешләр белән) (алга таба - Устав)

- «Опека һәм попечительлек өлкәсендәге вәкаләтләрне тапшыру турында» Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 04 июлендәге 2785 номерлы карары;

- «Опека» идарәсен төзү турында» Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2008 елның 10 июлендәге 1602 номерлы карары белән расланган «Опека» идарәсен төзү турында нигезләмә белән.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека-суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган гражданнарны урнаштыру формасы, аның барышында опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) опекага алынган балаларның законлы вәкилләре булып торалар һәм аларның исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик әһәмияткә ия гамәлләр башкаралар;

- тәрбиягә алынучы (подопечный) - опека яисә попечительлек билгеләнгән граждан;

- эшкә сәләтсез граждан - РФ ГК 29 статьясында каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган граждан;

- эшкә сәләтлелеге чикләнгән - РФ ГК 30 статьясында каралган нигезләр буенча эшкә сәләтлелеге чикләнгән граждан.

2. Хезмәт күрсәтү стандарты

| Стандарт таләпләренең исеме | Стандарт таләпләре эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 2.1. Хезмәтнең исеме | Тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен опекунга рөхсәт бирү. | РФ ГК; 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон; ТР Законы 2004 елның 27 феврале № 8-ТРЗ |
| 2.2. Хезмәт күрсәтүче орган исеме | Тәрбиягә алынучыны (подопечный) теркәү урыны буенча «Опека» идарәсе. | Устав, 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы |
| 2.3. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен опекунга рөхсәт бирү турнда карар яисә тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен опекунга рөхсәт бирү турында баш тарту. | РФ ГК; 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон; 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы ТР Законы |
| 2.4. Хезмәтне күрсәтү срогы | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документларны алганнан соң 15 эш көне эчендә. Карарны әзерләү башка оешмаларга запрослар җибәрүне яисә өстәмә консультацияләр бирүне таләп иткән очракта, башкарма комитет җитәкчесе карары буенча мөрәҗәгатьне карау срогы 30 көнгә кадәр озайтылырга мөмкин. | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | (Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар 15 эш көне эчендә кабул ителә. Тиешле карар мөрәҗәгать итүчегә почта аша җибәрелә, я кабул иткәндә турыдан-туры бирелә). | |
| 2.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәкъдим итү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1) опекунның тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен рөхсәт алу турындагы гаризасы (опекага алынган затның милкенә хокук алмыйча);<br>2) опекун вазыйфаларын башкаручы учреждение администрациясенең әлеге учреждениедә озак вакыт дәвамында торучы эшкә сәләтсез зат карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен рөхсәт турындагы гаризасы (опекага алынган затның милкенә хокук алмыйча);<br>3) торак гомуми өлешле милектә булса, наемга алу шарты белән тәэмин ителүченең торак тапшыруга ризалыгы турындагы гаризасы (булган очракта);<br>4 опека билгеләү һәм опекун билгеләү турында норматив хокукый акт (карар);<br>5) гражданны эшкә сәләтсез дип тану турында суд органы карары;<br>6) тәрбиягә алынучының (подопечный) (эшкә сәләтсез кешенең) паспорт күчермәсе;<br>7) гражданнар милкенә фатир (йортлар) тапшыру буенча килешү күчермәсе;<br>8) тәрбиягә алынучының (подопечный) мөстәкыйль яшәү мөмкинлеге булмау турында медицина бәяләмәсе;<br>9) тәрбиягә алынучыны (подопечный) торак белән тәэмин итү турында килешү проекты күчермәсе. | РФ ГК;<br>2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2004 елның 27 феврале № 8-ТРЗ |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы хезмәтләр күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | - Тәрбиягә алынучының (подопечный) (эшкә яраксыз затның) мөлкәте турында Бердәм дәүләт хокук реестрыннан (дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе) алынган мәгълүмат;<br>- Йорт (фатир) кенәгәсеннән идарәче компания яки торак милекчеләре ширкәтеннән өземтә. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда килештерү хезмәт күрсәтү өчен таләп ителә һәм хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү хезмәте таләп ителми. | |
| 2.8. Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Тапшырылган документларның 2.5 пунктта күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>2. Бирелә торган документларда кире килешенмәгән төзәтмәләр булу. | |
| 2.9. Хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәтне күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:<br>- дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен нигезләр булмау;<br>- мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;<br>- тәрбиягә алынучыны (подопечный) гражданлык һәм милек хокукларында кысу;<br>- гариза бирүче тарафыннан бирелгән | РФ ГК; 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы ТР Законы |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | документларда ачыкланган дөрес булмаган яки ялган мәгълүматлар. | |
| 2.10. Хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Хезмәт бушлай бирелә. | |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Хезмәт күрсәтү турында сорау биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта максималь көтү вакыты | Хезмәт алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.<br>Хезмәт алучыга (мөрәҗәгать итүчегә) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне көтү) максималь көтү срогы 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү срогы | Бер көн эчендә. | |
| 2.14. Хезмәт күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр | 1. Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә ашырыла.<br>2. «Опека» идарәсе белгеченең мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү бинасында эш урыны электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәт күрсәтүне тулы күләмдә оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>3. Документлар тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазлана һәм документларны тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә. | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 2.15. Хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Хезмәт күрсәтүнең һәркемгә дә уңайлы булуы күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>- бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>- гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү башкарыла торган кирәкле санда белгечләр, шулай ук биналар булу;<br>- мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендәге Башкарма комитетның мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Хезмәт күрсәтү сыйфаты булмау түбәндәгеләр белән характерлана:<br>- документлар кабул итү һәм бирү өчен чиратлар;<br>- хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтләренә карата шикаятьләр.<br>Күп функцияле үзәктә хезмәт күрсәтелми.- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтләренә карата шикаятьләр. | |
| 2.16. Электрон формада хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Хезмәт күрсәтү тәртибе турында консультацияне башкарма комитетның Интернет – кабул итү бүлмәсе аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада хезмәт күрсәтелми. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Хезмәт күрсәткәндә хәрәкәт тәртибен тасвирлау.

3.1.1. Хезмәт күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- Опекуннарга опекунлык бурычларын үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү һәм консультация бирү; опекунлыкка алынучының торагын наемга бирү өчен рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча опекуннарга мәгълүмат һәм консультация бирү (милеккә хокук алмыйча);
- гаризалар һәм документлар кабул итү, аларны теркәү;
- тапшырылган документларны кабул итү яки баш тарту өчен нигез билгеләү өчен аларның әлеге административ регламент таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерү;
- бердәм дәүләт хокук реестрыннан (дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе) тәрбиягә алынучының (подопечный) (эшкә яраксыз затның) милке турында мәгълүмат соратып алу; Идарәче компаниягә яки торак милекчеләре ширкәтенә йорт (фатир) китабыннан өземтә бирү турында запрос җибәрү;
- хезмәт күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелек блок-схемасы регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән.

3.2. Опекунның «Опека» идарәсенә мөрәҗәгать итүе административ процедураны башлау өчен нигез булып тора. Опекун «Опека» идарәсе белгеченә паспорт, ә Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, аның шәхесен таныклаучы башка документ; опекун билгеләү һәм опекун билгеләү турындагы норматив хокукый акт (карар), яисә опекунлык таныклыгы күрсәтә.

Гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы «Опека» идарәсе белгече мәгълүмат бирү һәм консультация бирү процедуралары кысаларында:

- хезмәт күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;
- опекунны тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны (тәрбиягә алынучының (подопечный) милкенә хокук алмыйча) наемга тапшыру өчен рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча хезмәт күрсәтү тәртибе белән таныштыра;
- тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны (тәрбиягә алынучының (подопечный) милкенә хокук алмыйча) наемга тапшыру өчен рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген тәкъдим итә;
- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза язу рәвеше турында аңлата.

Консультация телдән мөрәҗәгать иткән көнне үткәрелә.

Хезмәт күрсәтүне башлап җибәрүче запросны бирү гариза бирүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, тапшырыла торган документация формасы һәм хезмәт күрсәтүнең башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

Консультация һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедураларны үтәүнең гомуми срогы-15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыручы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, консультацияләрнең тулылыгы, грамоталылыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы өчен шәхси җавап тота.

3.3. Документларны кабул итү буенча административ процедураны гамәлгә ашыра башлау өчен мөрәҗәгать итүче әлеге административ регламентның 2.5 пунктында каралган гариза һәм документларны тапшыра.

Гаризалар һәм документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч әлеге административ регламентның 2.5 пункты нигезендә, шул исәптән, барлык кирәкле документларның комплектлылыгын һәм булуын тикшерә:

- гражданинның шәхесен билгели - шәхесне таныклаучы документны, шулай ук опека билгеләү турында норматив-хокукый актны тикшерә;

- опекун тарафыннан бирелгән барлык кирәкле документларның булу-булмавы һәм билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

- документлар тутыруның дөреслеген тикшерә;

- документлардагы текстлар аңлаешлы һәм карандаш белән язылмаганлыгын билгели;

- документларда ассызыклаулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм, төзәтүләр юклыгын, шулай ук документларда эчтәлеген төгәл аңлатырга мөмкинлек бирмәүче зарарланулар булмавын билгели;

- кергән документларны терки;

- формирует пакет документов для предоставления государственной услуги по вопросам выдачи разрешений на сдачу жилья, принадлежащего подопечному, в наем.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар

Максималь башкару вакыты 15 минут тәшкил итә.

Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү процедураларының дөрес үтәлеше өчен шәхси җавап тота.

3.3.1. «Опека» идарәсе белгече тиешле органнарга түбәндәге сорауларны җибәрә: Бердәм дәүләт хокук реестрыннан (дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе) тәрбиягә алынучының (подопечный) (эшкә яраксыз затның) милке турында; йорт (фатир) китабыннан (идарәче компания яки торак милекчеләре ширкәте) өземтә бирү турында.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәрбиягә алынучының (подопечный) (эшкә сәләтсез затның) милке турында бердәм дәүләт реестрыннан өземтә, яшәү урыныннан йорт (фатир) китабыннан өземтә бирү турында җибәрелгән запрослар.

Максималь гамәлдә булу срогы 3 көн тәшкил итә.

3.3.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә мәгълүматлар белән тәэмин итүче белгеч соратып алына торган документларны (мәгълүматларны) бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, әгәр дә ведомствоара запрос әзерләү һәм ведомствоара таләпкә җавап җибәрүнең федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса, документ һәм мәгълүмат бирүче оешмага кергән көннән соң 5 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (белешмәләр) яисә башкарма комитетка җибәрелгән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.4. Кирәкле документлар булмау, бирелгән документларның регламент таләпләренә туры килмәве, гаризада яки тапшырылган документларда туры килмәве, яки гаризада кирәкле белешмәләр булмаган очракта опекуннан документлар кабул итү өчен җаваплы хезмәткәр хезмәт күрсәтү өчен ачыкланган каршылыклар исемлеген формалаштыра һәм гариза бирүчегә тапшырылган документлар белән бергә тапшыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган Документлар

Максималь башкару вакыты 15 минут тәшкил итә.

3.4.1. Опекун яисә попечитель риза булмаганда, җитешмәгән яисә төзәтелгән, яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән документларны, йә аларны бирү мөмкин булмаган документларны, шулай ук баш тарту өчен башка нигезләр булганда, белгеч мөрәҗәгать итүче (опекун) адресына хезмәт күрсәтү өчен каршылыклар булу турында язма хәбәр әзерли, анда аларны бетерү буенча чаралар күрергә тәкъдим ителә һәм «Опека» идарәсе башлыгына язма хәбәрне тапшыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты.

Гамәлдә булуның максималь вакыты-бер көн.

3.4.2. Хезмәт күрсәтү өчен киртәләр булу турында имзаланган язма хәбәр опекунга яки попечительгә кулына бирелә яки почта аша җибәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: язмача хәбәр җибәрелде.

Максималь үтәү срогы-тиешле карар кабул ителгәннән соң 3 көн.

3.5. «Опека» идарәсе белгече опекунга тәрбиягә алынучыны (подопечный) торак белән тәэмин итү өчен рөхсәт турында күрсәтмә проектын әзерли.

Максималь башкару срогы гамәлләр 3 көн.

3.5.1. «Опека» идарәсе белгече опекунга тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны (тәрбиягә алынучының (подопечный) милкенә хокук алмыйча) наемга тапшыру өчен яки опекунга тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны (тәрбиягә алынучының (подопечный) милкенә хокук алмыйча) наемга тапшыру өчен күрсәтмә бирүдән баш тарту турында боерык әзерли.

Бу эш буенча документлар пакетын кул астындагының шәхси эшенә төшерәләр.

Процедураларның нәтиҗәсе: «Опека» идарәсе башлыгына кул куярга җибәрелгән опекунга тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны (тәрбиягә алынучының (подопечный) милкенә хокук алмыйча) наемга тапшыру турындагы боерык яки опекунга тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен күрсәтмә бирүдән баш тарту турында боерык.

Максималь башкару срогы-бер көн.

3.5.2. «Опека» идарәсе башлыгы нәтиҗәне, проектне карый һәм опекунга тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны (тәрбиягә алынучының (подопечный) милкенә хокук алмыйча) наемга тапшыру турындагы боерыкка яки опекунга тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен күрсәтмә бирүдән баш тарту турында боерыкка имза сала.

Процедураларның нәтиҗәсе: кул куелган боерык.

Максималь гамәлдә булу срогы-3 көн.

3.5.3. Кул куелган бер нөсхә почта аша җибәрелә яки опекунга шәхсән тапшырыла, икенчесе-опекага алынган затның шәхси эшенә теркәлә, өченчесе чыгучы документларда теркәлә.

Процедураларның нәтиҗәсе: «Опека» идарәсе белгече опекунга тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны (тәрбиягә алынучының (подопечный) милкенә хокук алмыйча) наемга тапшыру турындагы боерык яки опекунга тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен күрсәтмә бирүдән баш тарту турында боерыкны бирә.

Максималь гамәлдә булу срогы-3 көн эчендә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Хезмәт күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын контрольдә тоту мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләү, опека һәм попечительлек органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып торалар:

- «Опека» идарәсе тарафыннан хезмәтләр күрсәтү буенча документлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектлар визасы тора;
- эш башкаруын билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;
- билгеләнгән тәртиптә хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен контрольдә тоту тикшерүләре үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда хезмәт күрсәтүгә (комплекслы тикшерүләр) бәйле барлык мәсьәләләр яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча карала ала.

Хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә, гамәлләрне башкаруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатыннан, «Опека» идарәсе башлыгына хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Административ процедуралар, карарлар кабул итү, белгечләр тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларның читкә чыгарылуын контрольдә тоту «Опека» идарәсе башлыгы, район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы (опека һәм попечительлек органы белгече) мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплы.

4.5. Дәүләт хезмәтләрен гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан күрсәтүне контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Опека» идарәсе эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алганда гамәлгә ашырыла.

4.6. «Опека» идарәсе башлыгы әлеге регламентта күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

## 5. Хезмәт күрсәтүче органнар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләр гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә, электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр дәүләт хезмәте күрсәтүче югары органга бирелә. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле

үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга яисә Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка бирелә.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны теркәү вакытын бозу.

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, күпфункцияле үзәк хезмәткәренә (карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына)) шикаять белдерелә торган очракта, тиешле дәүләт хезмәтләрен тулы күләмдә, 210 номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, тиешле тәртиптә бирү функциясе йөкләнә ала;

3) мөрәҗәгать итүчедән документлар яисә мәгълүматка карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен муниципаль хокукый актларда каралмаган гамәлләрне ашыруны яисә тапшыруны таләп итү;

4) Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен муниципаль хокукый актларда каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр баш тарту нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, күпфункцияле үзәк хезмәткәренә (карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына)) шикаять белдерелә торган очракта, тиешле дәүләт хезмәтләрен тулы күләмдә, 210 номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, тиешле тәртиптә бирү функциясе йөкләнә ала;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, органның вазыйфаи заты яисә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210 номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешендә каралган оешмаларның дәүләт яисә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуы. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, күпфункцияле үзәк хезмәткәренә (карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына)) шикаять белдерелә торган очракта, тиешле дәүләт хезмәтләрен тулы күләмдә, 210 номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, тиешле тәртиптә бирү функциясе йөкләнә ала;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, күпфункцияле үзәк хезмәткәренә (карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган очракта, тиешле дәүләт хезмәтләрен тулы күләмдә, 210 номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, тиешле тәртиптә бирү функциясе йөкләнә ала;

10) мөрәҗәгать итүчедә, әлеге Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат биргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, мөрәҗәгать итүченең таләбе. Күрсәтелгән очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, күпфункцияле үзәк хезмәткәренә (карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган очракта, 210 номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү функциясе йөкләнгән.

5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьне дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәткәрнең, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең төбәк порталыннан файдаланып, почта аша, күпфункцияле үзәк аша җибәрергә мөмкин, шулай ук гариза бирүченең шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин. Күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең төбәк порталыннан файдаланып, почта аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүченең шәхси кабул итүе вакытында кабул ителергә мөмкин. Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять, шулай ук аларның хезмәткәрләренең Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең региональ порталыннан файдаланып, почта аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителә ала.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга кергән шикаять аны теркәгән көннән алып унбиш көн эчендә каралырга тиеш, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күп функцияле үзәктән баш тартткан очракта, мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итү яисә җибәрелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылуга шикаять бирелгән очракта - теркәлгән көннән биш көн эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның

вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәрнең исеме;

2) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүче - физик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) һәм гариза бирүчегә җибәрелергә тиешле почта адресы (булган очракта) ;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр (Регламентка 2 нче кушымта);

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятькә дәүләт хезмәте күрсәтүче кеше тарафыннан кул куела.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарын төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Мөрәҗәгать итүчегә әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивацияле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять мөрәҗәгать итүчегә бирелгән җавапта канәгатьләндерергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында мөрәҗәгать итүчегә башкарырга кирәк булган алга таба гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять мөрәҗәгать итүчегә биргән җавапта канәгатьләндерелмәгән дип таныган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат (хезмәткәр) булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Район
башкарма комитеты җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары А.Н. Подовалов

Тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең БЛОК-СХЕМАсы

Тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру өчен опекунга рөхсәт бирү буенча мәгълүмат һәм консультация бирү

↓

Документларны кабул итү һәм теркәү

↓

Тапшырылган документларны, андагы белешмәләрнең тулылыгын тикшерү

↓

Тәрбиягә алынучының (подопечный) (эшкә сәләтсез затның) милеге турында ЕГРПнан һәм йорт (фатир) китабыннан өземтә бирү турында запрослар җибәрү

↓

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрос нигезендә мәгълүматларны җиткерүче документларны (белешмәләрне) бирүдән баш тарта яисә кире кага.

↓

Дәүләт хезмәте күрсәтүдә яки баш тартуда нигезләрне билгеләү

↓

Тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру турында боерык әзерләү

Тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшырудан баш тарту турында боерык әзерләү

↓

Тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшыру турында яисә тәрбиягә алынучы (подопечный) карамагындагы торакны наемга тапшырудан баш тарту турында боерыкны тапшыру

Тәрбиягә алынучы (подопечный)
карамагындагы торакны наемга
тапшыру өчен опекунга рөхсәт бирү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне
контрольдә тотучы вазыйфаи затлар
РЕКВИЗИТЛАРЫ

Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты

| Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Лаптева Светлана Владимировна | Район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары | 39-01-05 | Svetlana.Lapteva@tatar.ru |

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы

| Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Павлова Инна Анатольевна | «Опека» идарә башлыгы | 32-89-26 | Inna.Pavlova@tatar.ru |